**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл жирлеге Заречье торак пунктында гражданнар дан үзара салым кертү турында

**05 декабрь 2021 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Заречье торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Заречье торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә узара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Заречье торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр һәм эшләр өчен түләү);

- Заречье торак пунктында җирлекне яктырту Һәм буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы: И.Б. Бохарова